**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** 11.06.2026

Казан ш.

**БОЕРЫК** 642-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында» 18.09.2023 №1084-п боерыгы белән расланган (24.06.2024 № 701-п, 05.08.2024 № 861-п, 01.07.2025 № 718-п боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә. Күрсәтелгән акт белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара»;

2.2 нче пунктның “а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) министрның беренче урынбасары (Комиссия рәисе), министр урынбасары (Комиссия рәисе урынбасары), дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше

өчен җаваплы вазыйфаи заты (комиссия сәркатибе), дәүләт хезмәте һәм кадрлар, хокукый тәэмин итү бүлегеннән, Министрлыкның министр тарафыннан билгеләнә торган башка бүлекчәләреннән дәүләт хезмәткәрләре»;

3.1 нче пунктның “а” подпунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне дәүләт хезмәткәрләренә бирү турында;»;

3.11 нче пунктның “а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы дип билгеләргә;»;

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында биләве коррупция куркынычы белән бәйле, биләве вакытында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында” (03.10.2016 №1007-п, 20.03.2018 № 233-п, 04.02.2019 № 84-п, 19.11.2019 № 1266-п, 12.10.2020 №1127-п, 25.11.2021 № 1301-п, 20.03.2023 № 296-п, 17.01.2024 № 35-п, 11.12.2024 № 1382-п, 06.02.2026 № 97-п боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 17.08.2016 ел, № 770-п боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерыкның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында биләве коррупция куркынычы белән бәйле, биләве вакытында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте

һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында биләве коррупция куркынычы белән бәйле, биләве вакытында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге Исемлеген (алга таба - Исемлек) расларга.»

2 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвен тәэмин итәргә.

4. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Министр А.И. Җиһаншин